ГЛАВА НИЖНЕШАНДЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1, с. Зюри, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422153

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ШҮЛӘҢГЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Мәктәп ур., 1 нче йорт, Җөри авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422153

тел.(факс): (85563) 3-87-31; e-mail: Nsnd.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление | Карар
19 октябрь 2020 ел | №9

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлегенең Җөри авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Шүләңгер авыл җирлеге муниципаль берәмлеге" Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Җөри авылы , Советская урамы , 7 А нче йорт адресы буенча урнашкан Җөри авылы мәдәният йорты бинасында 2020 елның 12 ноябрь сәгать09.00 Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлегенең Җөри авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлегенең Җөри торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Җөри авылы, Коммунистлар урамы ягына баручы юлны вакташ җәеп ремонтлау; (сатып алу, ташу, вак таш җәю, түләү буенча эш килешүе);

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге башкарма комитетына Җөри авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Шүләңгер
авыл җирлеге башлыгы: Е.М.Михайлова